РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**2019елның 4 нче сентябре** **Чистай шәһәре** **№37/2**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2018 елның 29 августында кабул ителгән “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының(тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) бердәм дәүләт реестрына кертелгән кулланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләве билгеләү тәртибен һәм “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган Россия Федерациясе халыкларының файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) физик һәм юридик затларга арендага бирү тәртибен раслау турында”гы 27/3 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2018 елның 29 августында кабул ителгән «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының(тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) бердәм дәүләт реестрына кертелгән кулланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләве билгеләү тәртибен һәм “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган Россия Федерациясе халыкларының файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) физик һәм юридик затларга арендага бирү тәртибен раслау турында”гы 27/3 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) турында”гы 2002 елның 25

июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1 статьясындагы 7 пункты белән, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына таянып, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлешенең 10 пунктчасын күздә тотып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы”;

1.2. Россия Федерациясе халыкларының кулланылмый торган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкярләрне) арендага бирү тәртибенең 5, 6, 8, 12 пунктларында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган Россия Федерациясе халыкларының файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) физик һәм юридик затларга “Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы” сүзләрен тиешле килеш кушымчасын кулланып, “Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты” сүзләренә алмаштырырга.

1.3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге милкенә караган канәгатьләнмәслек хәлдә булган Россия Федерациясе халыкларының кулланылмый торган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкярләрне) арендага физик һәм юридик затларга бирү тәртибенә бәндәге пунктны өстәргә:

«17. Гамәлдәге законнар нигезендә, мәдәни мирас объектын арендалау килешмәсе төзү белән бер үк вакытта арендатор белән мәдәни мирас объекты урнашкан җир кишәрлеген арендалау килешмәсе төзелә.

Җир кишәрлеген арендалау килешмәсе мәдәни мирас объектын арендалау килешмәсе төзелгән көннән соң 60 көннән дә соңга калмыйча төзелә.

Әгәр җир кишәрлеге мәдәни мирас объектының фундаменты обрезы буенча формалашса, җир кишәрлеген арендалау килешүе төзелми. Бу очракта мәдәни мирас объектын арендалау шартнамәсенә мәдәни мирас объектының фундаменты обрезы буенча төзелгән җир участогының бер өлеше өчен аренда түләве кертелә. Җир кишәрлеге өчен аренда түләве күләме җир кишәрлекләре өчен аренда түләвен билгеләү тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

Әгәр җир участогы формалашмаган һәм кадастр исәбенә куелмаган булса, шул ук вакытта арендатор тарафыннан мәдәни мирас объекты янындагы территория файдаланылмый икән, аренда килешүе төзү таләп ителми. Бу очракта мәдәни мирас объектын арендалау шартнамәсенә мәдәни мирас объектының фундаменты обрезы буенча исәпләнгән, җир участогының бер өлеше өчен түбәндәге формула буенча исәпләнгән аренда түләве кертелә:

$$ПР = \frac{Рап \times Пзу \times N}{12}$$

Пр- Объект астындагы җир кишәрлеге өчен түләү күләме;

Рап- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Җир өчен аренда түләве турында” 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары нигезендә исәпләнгән еллык аренда түләве күләме, кв. м өчен сум.

Пзу- объект урнашкан мәйдан, кв. м.

N- объектлар урнашкан вакыт аралыгына айлар саны».

2. Әлеге карарны “Чистопольские Известия” (“Чистай хәбәрләре”) газетасында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О. В.Добронравовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А.Иванов